ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы халкын транспорт белән тәэмин итү турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы транспорт һәм юллар хуҗалыгы министры Ф.М. Хәнифовның Татарстан Республикасы халкын транспорт белән тәэмин итү турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы транспорт һәм юллар хуҗалыгы министры Ф.М. Хәнифовның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында, шәһәр яны элемтәсе тимер юл һәм су транспортында пассажирлар йөртүне, шулай ук региональ һава транспортында пассажирларны йөртүне гамәлгә ашыра торган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү эшен дәвам итәргә.

2.2. Территорияләрдәге транспорттан һәркем файдалана алуны һәм халыкның мобильлеген арттыру максатларында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында рентабельле булмаган, ләкин социаль әһәмияткә ия даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча һәм даими пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутлары буенча даими пассажирлар йөртүне оештыруга чыгымнарны каплау эшен дәвам итәргә.

2.3. Автомобиль пассажирлар транспортының һәм шәһәр җир өсте электр транспортының күчмә составын модернизацияләүгә дәүләт ярдәменең, шул исәптән бюджеттан тыш чыганакларны дәүләти-хосусый партнерлык шартларында җәлеп итеп, нәтиҗәле механизмнарын әзерләү (даими эшләүче механизмнарын булдыру) мәсьәләсен эшләп бетерергә.

2.4. «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм

багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 3 маендагы 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ комплекслы планын һәм региональ стандартын үз вакытында әзерләүне һәм раслауны тәэмин итәргә.

2.5. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру мәсьәләләрен регламентлаштыра торган законга караган кирәкле норматив хокукый базаны булдыруны тәэмин итәргә.

2.6. Халыкның гарантияле, һәркем файдалана алырлык һәм куркынычсыз пассажирлар йөртү ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган Татарстан Республикасы транспорт челтәрен нәтиҗәле, балансды үстерү максатларында «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатларына һәм бурычларына ирешүне тәэмин итәргә, программаның нәтиҗәлелегенә анализ ясарга һәм кирәк булганда аңа үзгәрешләр кертергә.

2.7. Илебездәге тәҗрибәне һәм чит ил тәҗрибәсен исәпкә алып, пассажирларның барлык категорияләренә, шул исәптән инвалидларга һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренә, хезмәт күрсәтүләрнең киң спектрын күрсәтә торган заманча автовокзаллар системасын булдыру мөмкинлеген карарга.

2.8. Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге авиатранспорт инфраструктурасын алга таба булдыру максатларында аэровокзал комплекслары куәтләрен алга таба үстерү чараларын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

2.9. Транспорт предприятиеләренең күчмә составына хезмәт күрсәтү һәм аны ремонтлау өчен кирәкле җиһазларның стратегик запасын булдыру мөмкинлеген карарга. Транспорт предприятиеләренең күчмә составына хезмәт күрсәтү өчен җиһазлар китереп тапшыру срокларын кыскарту максатларында Татарстан Республикасы территориясендә кирәкле комплектлау әйберләрен һәм җиһазларны җитештерүне җайга салу мөмкинлеген карарга.

2.10. Халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын арттыру максатларында файдаланучыларга күчерү юлы белән түләү ысулларының максималь төрлелеге мөмкинлеген бирә торган цифрлы пассажирлар сервисын үстерүне тәэмин итәргә.

2.11. Транспорт тармагын кадрлар белән тәэмин итү торышына мониторинг үткәрергә һәм транспорт комплексы һөнәрләренең җәлеп итүчәнлеген арттыру чараларын эшләргә.

2.12. Транспорт тармагы өчен кадрлар әзерләү срокларын кыскарту максатларында укытуның яңа нәтиҗәле рәвешләрен һәм яңа технологияләр кертергә, шулай ук йөртүчеләрне онлайн-укыту форматында эштән аермыйча

укытуның яңа уку-укыту программаларын башлап җибәрү мөмкинлеген карарга.

2.13. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгы базасында пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә бердәм методика нигезендә муниципаль белгечләрне әзерләү буенча компетенцияләр үзәген булдыру мөмкинлеген карарга.

2.14. Транспорт предприятиеләре чыгымнарын оптимальләштерү максатларында транспортта йөргән өчен турыдан-туры түләгәндә һәм күчерү юлы белән түләгәндә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хезмәтләре күрсәтүгә дифференциацияләнгән тарифны билгеләү мөмкинлеген карарга.

2.15. Горький һәм Куйбышев тимер юллары – «РЖД» ачык акционер җәмгыяте филиаллары белән берлектә шәһәр яны элемтәсе тимер юл транспортының яңа тукталыш платформаларын, янәшәдәге территорияләрне төзекләндереп, капиталь ремонтлау һәм төзү программасын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

2.16. Эчке сулар транспортында пассажирлар йөртүне үстерү максатларында «Татарстан Республикасы флоты» акционер җәмгыяте белән берлектә елга транспорты инфраструктурасын (причаллар, портлар, причал корылмалары) торгызу һәм булдыру, шулай ук яңа маршрутлар, шул исәптән регионара маршрутлар, ачу мөмкинлеген карарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2088-VI ДС